СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» апрель 2025 ел № 124

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, һәм аның график билгесен кертеп, 2025 елның 18 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгару (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Пыжмара авылы, С.Мөлеков ур., 19 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар басылып чykканнан соң үз көченә керә.


Пыжмара авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе Р.Х.Заляев

Пыжмара авыл җирлеге
Советының 14 апрель 2025 елда
кабул ителгән 124 нчы карарына
1 кушымта

# Пыжмара авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы


| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Беренче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Пыжмара авылының Новая урамы, С. Мөлеков урамының 1 дән 17 А так сандагы, 2 дән 26 нчы җөп сандагы йортлары кереп | 90 |
| 2 | **Икенче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Пыжмара авылы Молодежная урамы, С.Мөлеков урамының 29 дан 55 нче так сандагы, 30 дан 78 нче җөп сандагы йортлары кереп | 80 |
| 3 | **Өченче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Пыжмара авылы Г.Тукай урамы кереп | 97 |
| 4 | **Дүртенче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Сәрдек авылы Мир урамының 1 дән 45 нче так сандагы, 2 дән 18 нче җөп сандагы йортлары кереп | 80 |
| 5 | **Бишенче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Сәрдек авылы Мир урамының 49 дан 63 нче так сандагы, 26 дан 52 нче җөп сандагы йортлары, Иске Пукшинер авылы Дружба урамы кереп | 80 |
| 6 | **Алтынчы номерлы Пыжмара сайлау округы** | Әтнә авылы Малая урамы, Комсомол урамының 1 дән 37 нче так сандагы һәм 2 дән 20 нче җөп сандагы йортлары, Югары Сәрдек авылының Заря урамы кереп | 97 |
| 7 | **Җиденче номерлы Пыжмара сайлау округы** | Әтнә авылы Искандаров урамы, Комсомол урамының 39 дан 73/1 нче так сандагы, 24 тан 36 нчы җөп сандагы йортлары кереп | 96 |

Пыжмара авыл җирлеге
Советының 14 апрель 2025 елда
кабул ителгән 124 нчы карарына
2 кушымта




с.Сардек

дер.Старый Пукшинер



с.Атня




дер. Верхний Сардек

